**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

29.08.2018

№ 280

**Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен гадәттән тыш хәл режимын бетерү турында**

Азык-төлек иминлегенә янаган хәвефнең һәм гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләренең бетерелүенә юнәлдерелгән чаралар тәмамлану белән бәйле рәвештә:

1. Татарстан Республикасының Азнакай, Актаныш, Әлки, Әлмәт, Апас, Баулы, Бөгелмә, Зәй, Зеленодольск, Кайбыч, Лениногорск, Мөслим, Яңа Чишмә, Нурлат, Сарман, Чирмешән һәм Ютазы муниципаль районнарының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен гадәттән тыш хәл режимын бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен гадәттән тыш хәл режимы кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 255 номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ